РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«28» октябрь 2022 ел г. Альметьевск № 2489

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмаган Әлмәт муниципаль районының аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренә хезмәте хакы түләү шартлары турында» 2018 елның 25 июнендәге 864 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмаган аерым оешмаларда эшләүчеләрнең вазыйфаи окладларын арттыру турында» 2022 елның 22 августындагы 878 номерлы карары нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмаган Әлмәт муниципаль районының аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренә хезмәте хакы түләү шартлары турында» 2018 елның 25 июнендәге 864 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 11 декабрендәге 1827 номерлы, 2022 елның 28 гыйнварындагы 99 номерлы, 2022 елның 17 мартындагы 419 нчы номерлы, 2022 елның 26 сентябрендәге2102 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. Карарга 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Башкарма комитетының
«25» июнь 2018 ел № 864
карары белән расланган
1 нче кушымта

Зак. № 305-2000

Әлмәт муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган Әлмәт муниципаль районы бюджет өлкәсендә аерым оешмалар җитәкчеләренең һәм белгечләренең вазыйфаи окладлары күләмнәре

| Вазыйфаның исеме | Вазыйфаи окладларның күләме, сум |
|---|---|
| Мөстәкыйль идарә (бүлек) җитәкчесе | 16 263 |
| Мөстәкыйль идарә (бүлек) җитәкчесе урынбасары | 15 785 |
| Бүлек җитәкчесе | 15 187 |
| Бүлек башлыгы урынбасары | 14 470 |
| Баш белгеч | 13 752 |
| Алып баручы белгеч | 13 035 |
| I категорияле белгеч | 12 198 |
| II категорияле белгеч | 12 078 |
| Белгеч | 11 958» |

1.2. Карарга 2 нче кушымтадагы таблицада «11 498» санын «11 958» саннарына алмаштырырга.

2. Бюджет өлкәсенең аерым оешмалары җитәкчеләренә аерым оешмалар хезмәткәрләренең өстәмә түләүләрен һәм башка түләүләрен билгеләү турында элек чыгарылган актларны әлеге карарга туры китерергә

3. Әлеге карарны газете «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

4. Бу карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2022 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А.Н. Подоваловка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе — А.М. Каюмов